ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» августа 2019 ел № 649

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 1218 нче номерлы “Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында” карары (2014 елның 14 февралендәге 96нчы номерлы, 2015 елның 29октябрендәге 1063 нче номерлы, 2017 елның 14 мартындагы 269 нчы номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 1218 нче номерлы “Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында” карары (2014 елның 14 февралендәге 96нчы номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 1063 нче номерлы, 2017 елның 14 мартындагы 269 нчы номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- "Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше» таблицасына түбәндәге юлны өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яшәү минимумыннан түбәнрәк (күпбалалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарсан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Ф.Р. Исмәгыйлевка йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе И.А.Галимуллин